# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«21» ноябрь 2016 ел № 10/5

**Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне раслау хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2014 елның 20 ноябрендәге «Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» 33/5 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
2. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә расларга.
3. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи үз-үзләрен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составын 2 кушымта нигезендә расларга.
4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык иминлеге буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев